# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылы торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2021 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 18 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2022 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Яхшы-Каран авылы Идрисов урамына вак таш түшәү;
2) Яхшы - Каран авылынды урам фонарьларын сатып алу һәм ;
3) Өлкәннәр көненә, инвалидлар көненә бүләкләр алу;
4) «Сабантуй» һәм «Яңа ел» бәйрәмнәрендә призлар һәм бүләкләр сатып алу;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 80 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 59 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 59 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Яхшы-Каран авылы Идрисов урамына вак таш түшәү;
2) Яхшы - Каран авылынды урам фонарьларын сатып алу һәм ;
3) Өлкәннәр көненә, инвалидлар көненә бүләкләр алу;
4) «Сабантуй» һәм «Яңа ел» бәйрәмнәрендә призлар һәм бүләкләр сатып алу;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Александровка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче А.Р.Гафиятуллин